ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2020 Казан ш. № 568-26/тко-2020

«Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифларны билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрларын билгеләргә.

4. «Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыятенә иректе файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә,

чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2020 № 568-26/тко-2020
карарына 1 нче кушымта

Каты коммуналь калдыкларны күмү буенча «Саба районы Шәмәрдән ТКХ МЖП» ачык акционерлык җәмгыяте өчен 2021 – 2025 елларга календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел | | 2024 ел | | 2025 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Саба муниципаль районы | | | | | | | | | | |
| 1 | «Саба районы Шәмәрдән ТКХ КҖП» ачык акционерлык җәмгыяте | 109,99 | 145,15 | 127,83 | 127,83 | 127,83 | 132,10 | 132,10 | 134,34 | 134,34 | 138,80 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2020 № 568-26/тко-2020
карарына 2 нче кушымта

Каты коммуналь калдыкларны күмү буенча «Саба районы Шәмәрдән ТКХ МЖП» ачык акционерлык җәмгыяте өчен 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| № п/п | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Саба районы Шәмәрдән ТКХ КЖП» ачык акционерлык җәмгыяте | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2021 | 4233,78 | 1 | 0 | - |
| | | 2022 | х | 1 | 0 | - |
| | | 2023 | х | 1 | 0 | – |
| | | 2024 | х | 1 | 0 | – |
| | | 2025 | х | 1 | 0 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге